ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1202 2016 елның 21 июле

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең 1.6. пунктында (алга таба - Тәртип) «һәм муниципаль предприятиеләр белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Тәртипнең 1.9. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Килешү процедуралары тәмамланганнан соң, Башкарма комитет бүлекчәсе җитәкчесе җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге белән берлектә административ регламент проектын Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыра.»;

Тәртипнең 1.10. пунктын төшереп калдырырга;

Тәртипнең 1.15., 1.16. пунктларында «икътисади анализ һәм транспорт бүлеге» сүзләрен «икътисади фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1.17. пунктында «икътисади анализ һәм транспорт бүлеге тарафыннан» сүзләрен «икътисади фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1.17. пунктында «Түбән Кама шәһәренең мәгълүмат үзәгенә» сүзләрен «җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 2.2. пунктындагы «в» пунктчасына «, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре» сүзләрен өстәргә;»;

Тәртипнең 2.4. пунктындагы «е» пунктчасына «, мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиеш булган документларга һәм мәгълүматка һәм мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы

документларга бүлеп, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш» сүзләрен өстәргә;

Тәртипнең 2.4. пунктындагы «м» пунктчасына «, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә;» сүзләрен өстәргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
җитәкче урынбасары Л.Р. Юнысов